ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БОРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

26.10.2021 | 2

с. Татарское Бурнашево

Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Юматово авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче ст., Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 12 нче ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Юматово авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Юматово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 нче елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Товар белән тәэмин итүче тарафыннан билгеләнгән пунктка кадәр китертеп, Юматово авылында юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу:

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Юматово авылы, Заречная урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан чиркәү бинасы янында үткәрергә.

4. Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетын халык җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин